ТР Теләче муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе - Югары Кибәхуҗа урта гомумбелем бирү мәктәбе филиалы “Кече Кибәхуҗа төп гомумбелем бирү мәктәбе”

# Ул, Алтын йолдызы булмаса да, чын Герой иде!

Эзләнү-тикшеренү эше



*Эшне башкарды:* Кече Кибәхуҗа төп гомуми белем бирү мәктәбенең 8 сыйныф укучысы **Вәлиева Резедә Зиннур кызы**

*Җитәкчесе:* Кече Кибәхуҗа төп гомуми белем бирү мәктәбенең музыка укытучысы **Мөхәмәдиева Наилә Дәүләтҗан кызы**

1941 - 1945

elenaranko.ucoz.ru

# “Ул, Алтын йолдызы булмаса да, чын Герой иде! ” дип аталган эшебезнең

**максаты:**

- **Авылдашым Морат Мостафинның тормыш юлын өйрәнү;**
- **Үземдә чорны тоемлау хисе формалаштыру, шәхси тормыш белән тарихи үсеш арасындагы бәйләнешне аңлату;**
- **Бөек Ватан сугышы турындагы белемнәрне барлау, сугыш афәтенең һәр кеше, һәр гаилә өчен фаҗига булуын күрсәтү;**
- **Эзләнү- тикшеренү аша үземнең интеллектуаль, иҗади, коммуникатив һәм оештыру сәләтләремне үстерү;**

**бурычлары:**

- **Бөек Ватан сугышы сугышчыларының каһарманлыгын бик ачык күрсәтүче дистәләрчә, йөзләрчә һәм меңнәрчә үлемсез батырлыкларның берсе булган Морат абый батырлыгын күрсәтү;**
- **Вакытлар һәм буыннар арасындагы бәйләнешне саклау;**
- **Өстәмә чыганаклардан файдаланып, фәнни эш язу күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү, фәнни фикерләү, фикерне исбат итү аша нәтиҗә чыгару.**

elenaranko.ucoz.ru

1941 - 1945



**Үлгәннәр истәлеге тереләр өчен кирәк. Тереләрнең җаны тыныч түгел. Дөнья тыныч түгел. Үлгәннәр турында даими сөйләргә кирәк. Вакытсыз үлгәннәр турында. Ир-егетләр турында. Алар онытылмаска тиеш. Алар хакы изге.**

**Ш. Рәкыйпов.**




Безнең Кече Кибәхуҗа авылы җирлегенә Олы Кибәхужа, Кече Кибәхужа, Казаклар авыллары керә. Бөек Ватан сугышына шушы бәләкәй генә авыллардан 291 кеше китә.


“Бер кайтмасак, бер кайтырбыз”, - дип китсәләр дә, 148 якташыбыз яу кырында мәңгелеккә ятып кала. Туган җирләре өчен башын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада.

Шундыйларның берсе - якташыбыз, Олы Кибәхужа авылында туган, шунда мөгаллим булып эшләгән **МОРАТ МОСТАФИН.**



elenaranko.ucoz.ru

1941 - 1945




Морат Мостафин 1916 елда Олы Кибәхуҗа авылында укытучы Әхмәтсафа Мостафин гаиләсендә дөньяга килә.

Җидееллык мәктәпне, аннары Алабуга техникумын уңышлы гына тәмамланганнан соң, Теләче районындагы Олы Кибәхуҗа, Югары Кибәхуҗа, Саурыш мәктәпләрендә мөгаллим булып эшли.

Эшләгән вакытында газетага мәкаләләр, хәбәрләр җибәреп тора. Язуга осталыгын күреп, аны Теләче район газетасына эшкә чакыралар.

elenaranko.ucoz.ru



Эзләнү-тикшеренү эшенә әзерләнгәндә, Морат Мостафин турында беренче мәгълүматны авылдашыбыз, Татарстан фәннәр академиясе академигы, философия фәннәре докторы Яхъя Абдуллинның “Үткәннәр һәм уйлар...” дигән китабыннан таптым.



*...1936 елның 11 март иртәсе.*

*... Мине 75 сум хезмәт хакы белән редакцияга техник сәркатип итеп эшкә алдылар. Морат абыйның хезмәт вазыйфасы - инструктор – массовик.*

*...Мин бу зат алдында һәр кайчан башымны иеп яшәдем. Күңеле саф, намуслы кеше иде. Эшли дә белде. Минем тормышымда күркәм роль уйнады. Аңа мәңгелек рәхмәтлемен.”*

[1] Абдуллин Я.Г. Үткәннәр һәм уйлар... Казан: Татарстан Фәннәр Академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2005. – 344 б. 58-59 нчы битләр.

elenaranko.ucoz.ru

# *Ул, Алтын Йолдызы булмаса да, чын Герой иде...*

1971 елда Татарстанга, Казаклар авыл Советына ерак Украинадан хат һәм җөмһүриятебезнең Теләче районында туып үскән элекке мөгаллим, журналист һәм Бөек Ватан сугышы партизаны Морат Мостафин турында гаҗәеп дулкынландыргыч язма килеп төшә.

Мин Морат абыйның сугышта күрсәткән батырлыгы турында Л.Е. Кизя язган хаттан укып белдем.


"... Легендар Сидор Артемьевич Ковпак җитәкчелек иткән партизаннар берләшмәсендә 1942 елның 25 маенда данлыклы татар халкының һәм бөтен совет халкының тугрылыклы улы, Татарстанның Теләче районы Олы Кибәхуҗа авылы егете Морат Әхмәтсафа улы Мостафин геройларча һәлак булды.

Мин Мостафинны яхшы белә идем, аның белән күп мәртәбәләр сугышта булдым. Мостафин кыю, Ватан-Анага чиксез бирелгән егет иде.

**Ул, Алтын йолдызы булмаса да , чын Герой иде!**

Бу турыда М.Ә. Мостафинның туганнарына хәбәр итүегезне үтенәм һәм дустым турындагы истәлекләремне юллыйм.

**Чын күңелдән хөрмәт белән -** С.А. Ковпак берләшмәсендәге элеккеге политрук, заманында Украина ССР Югары һәм махсус урта белем министры урынбасары булып эшләгән – **Л.Е. Кизя.** [1]


Уважаемые товарищи!
К Вам обращаются сотрудники Путивльского музея «Партизанской славы».
Ваш земляк Мустафин Мурат Ахметсафинович, 1911 г. рождения, находился в Путивльском партизанском отряде под командованием С. А. Ковпака.
В отряд он прибыл в апреле 1942 г.
Погиб 25 мая 1942 г. Похоронен у нас в Спадщанском лесу, в братской могиле.
В связи с празднованием 30-летия партизанского движения на Сумщине просим Вас найти его родных и прислать в музей «Партизанской славы» документы, фотографии и личные вещи Мустафина М. А. для пополнения экспозиции музея.
Заранее благодарим Вас.
30/X-71 г. Н/сотрудник Сазонова
Послали адрес и фотокарточки 26/XI-71 г.

Кушымта 3- Олы Кибахуҗага ерак Путивльдан хат...




*Олы Кибәхуҗага ерак Путивльдән хат...*

elenaranko.ucoz.ru

# Гаилә истәлекләре



Флера апа гаиләсе белән әтисенең каберлеге янында



Морат Мостафинның кызы Флера апа гаиләсе белән



Морат батыр әнисе Зәйнәпбикә апа белән



ВСТРЕЧА ЧЕРЕЗ 70 ЛЕТ...



ПУТЕШЕСТВИЕ В КАЗАНЬ

**Батырлык матбугат битләрендә...**

elenaranko.ucoz.ru

Сүзе,гомере бүленгән- “Кайтмый калганнар турында жыр” яза ул. Бик кирәк безгә мондый язучы:хәтер саекмасын,күңелләр коргаксымасын өчен кирәк!

Ш. Галиев.

Эзтабарларның “Хәтер яктысы” берләшмәсе (житәкчесе Шаһинур Мостафин)  Морат батырны эзләү, аның кылган батырлыгын, якты истәлеген киләчәк буыннар хәтеренә житкерү юнәлешендә зур көч-тырышлык куя.




Морат абый турындагы язмасы өчен без аңарга чиксез рәхмәтлебез.




elenaranko.ucoz.ru

# Менә алар – таныш өчпочмаклар – илчеләре сугыш кырының...

Сандык төпләрендә
Өчпочмаклы хатлар
Күз карасы кебек
саклыналар...
Ш.Мостафин

**“Дошман тылыннан хат.**

**Исәнмесез!**

**Барыгызга да сагынып кайнар сәлам! Күрше-колан, кардәш-ыруларның барчасына да сәлам, диярсез. Сәлам соңында шул: үзем хәзергә исән-сау. Менә нәкъ сигез айдан соң сезгә хат язарга мөмкинлек алдым. Үзем, узган елның октябреннән бирле, дошман тылында фашист этләренә каршы көрәшне дәвам иттерәм. Көннәр җылыну белән безнең эшчәнлек аеруча җанланып китте. Партизан отрядыбыз көннән-көн йөзләгән кадрлар белән тулылана бара.**

**Фашистларны көннәр һәм төннәр буенча кыра бирәбез, кая кереп посарга урын таба алмыйлар. Без алар хисабына коралланабыз, туенабыз һәм киенәбез. Ләкин ул кара җаннар хатын-кызлар һәм бала-чагаларны бик күп үтерәләр. Без юк урынга барып чыгып, авылларны барлык халкы белән бергә утта яндыралар...**

**Партизан исеме аларның йөрәкләренә инә урынына кадала...**

**Шулай итеп, без көрәштә көннән-көн чыныга киләбез. Тәҗрибә арта, эшебезнең хаклыгына, җиңүебезгә ышаныч көннән-көн ныгый.**

**Тирән дошман тылында сезне сагынып хат язучы,ерактан торып булса да кулыгызны яратып кысучы улыгыз – партизан Морат. Хушыгыз! Көтегез, кайтырмын!.. 2.V.42 ел”**





elenaranko.ucoz.ru

*“...Әлеге кош теледәй хат яраткан абыебызның безгә соңгы сәламе һәм изге васыяте булган икән...*

*Морат абыемның ул хатына каршы җавап та язган идем. Әмма хатым барып җиткәндә, абыем инде... Хатымның буш калган урынына партизан иптәше абыемның батырларча һәлак булуы турында берничә җөмлә язган иде,”*- дип искә ала батырның бертуган сеңлесе Ләбибә ханым Мостафина-Умерова.





**Морат батырның бердәнбер кызы- Флүрә апа. Әтисенең бик яраткан кызы булган ул. Икеләтә бәйрәм ясап, әтисенә нәкъ 20 яшь туласы көн алдыннан гына 1936 елның 13 июлендә дөньяга килгән нәни Флүрә. Хәзерге вакытта улы Марат, килене Гөлшат белән мәркәзебезнең Дәрвишләр бистәсендә яши.**



elenaranko.ucoz.ru



Украинаның Сумы өлкәсе Путивль шәһәреннән ерак түгел Спадшань урманында, татар егете **Морат Мостафин** соңгы батырлыгын күрсәткән урында, **мәрмәрдән һәйкәл** куелган.



elenaranko.ucoz.ru

# Батырлыктан үлемсезлеккә...

Үзең үлсәң,матур исемең калды,
Киң Ватанга даның таралды.
С. Урайский




Бөек Җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан, заманында ул укыган һәм укыткан Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбенә аның исеме бирелде. Безнең Кече Кибәхуҗа төп мәктәбендә Морат батыр призына спорт ярышлары үткәрелә.



2016 елның 7 маенда Олы Кибәхуҗа авылында 9 май бәйрәме уңаеннан парад митинг үтте. Парадның үзенчәлеге шунда булды, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә ясалган һәйкәл диварына Морат Әхмәтсафа улы Мостафинга истәлек тактасы куелды.

elenaranko.ucoz.ru





**Киләчәктә дә безнең күңелләрдә авылдашыбыз Морат Мостафин эзләре җуелмас, киресенчә, гомерлек булып уелыр. Илебез азатлыгы өчен көрәшкән солдатларны онытмыйк! Исәннәрнең кадерен белик, үлгәннәрнең каберен белик!**





elenaranko.ucoz.ru

*Игътибарыгыз өчен рәхмәт!*

elenaranko.ucoz.ru